| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНАРЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«30» март 2021 ел.**

**КАРАР**
**№ 4**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыруга шартнамә төзү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы Беркетмәсенең 24 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 24 февралендә 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыруга шартнамә төзү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 16 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчасын өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булуы.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы : Перфилов Ю.М.